| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «Об учреждении Постоянного представительства Республики Татарстан в Свердловской области»**

В целях совершенствования деятельности Постоянного представительства Республики Татарстан в Свердловской области **постановляю**:

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 25 мая 1996 года № УП-312 «Об учреждении Постоянного представительства Республики Татарстан в Свердловской области» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 3 июня 2002 года № УП-450 и от 14 мая 2016 года № УП-410) следующие изменения:

а) преамбулу изложить в следующей редакции:

«В целях установления, развития и расширения взаимовыгодных торгово-экономических, научно-технических, культурных и гуманитарных связей между Республикой Татарстан и Свердловской областью, руководствуясь Конституцией Республики Татарстан и Законом Республики Татарстан от 10 ноября 2003 года № 47-ЗРТ «О представительствах Республики Татарстан», **постановляю:**»;

б) в Положении о Постоянном представительстве Республики Татарстан в Свердловской области:

пункт 1.2 признать утратившим силу;

в пункте 1.5 слова «законодательством Республики Татарстан, законодательством Российской Федерации, Договором» заменить словами «законодательством Российской Федерации, законодательством Республики Татарстан»;

в абзаце втором пункта 2.2 слова «научных и культурных контактов, обменов» заменить словами «науки, культуры»;

в пункте 2.3:

в абзаце третьем слово «фирмами,» исключить;

в абзаце шестом слова «законодательству Республики Татарстан и Российской Федерации» заменить словами «законодательству Российской Федерации и законодательству Республики Татарстан»;

в абзаце седьмом слова «фирмам и» исключить;

дополнить новым абзацем двенадцатым следующего содержания:

«оказание содействия в сохранении объектов культурного наследия (памятников истории и культуры) народов Российской Федерации, сохранении и развитии культурно-национальной самобытности, защите и сохранении историко-культурной среды обитания, развитии культуры;»;

абзац двенадцатый считать абзацем тринадцатым;

в абзаце четвертом пункта 4.3 слова «Департаментом по делам государственных служащих при Президенте Республики Татарстан» заменить словами «Департаментом государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
01 февраля 2019 года
№ УП-49

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Свердловск өлкәсендәге даими вәкиллеген гамәлгә кую турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасының Свердловск өлкәсендәге даими вәкиллеге эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Свердловск өлкәсендәге даими вәкиллеген гамәлгә кую турында» 1996 елның 25 маендагы ПУ-312 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2002 елның 3 июнендәге ПУ-450 номерлы һәм 2016 елның 14 маендагы ПУ-410 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы һәм Свердловск өлкәсе арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, мәдәни һәм гуманитар элемтәләр урнаштыру, аларны үстерү һәм киңәйтү максатларында, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» 2003 елның 10 ноябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм:**»;

б) Татарстан Республикасының Свердловск өлкәсендәге даими вәкиллеге турындагы нигезләмәдә:

1.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.5 пунктта «Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе законнары, Шартнамә нигезендә» сүзләрен «Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктның икенче абзацында «фәнни һәм мәдәни элемтәләр, алмашулар» сүзләрен «фән, мәдәният» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктта:

өченче абзацта «фирмалар,» сүзен төшереп калдырырга;

алтынчы абзацта «Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе законнарына» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «фирмалар,» сүзен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле яңа унтугызынчы абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклап калуга, мәдәни-милли үзенчәлекләрне саклап калуга һәм үстерүгә, тарихи-мәдәни яшәү тирәлеген яклауга һәм саклауга, мәдәниятне үстерүгә булышлык итү;»;

уникенче абзацны унөченче абзац дип санарга;

4.3 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 01 февраль
№ ПУ-49